
# Нурчыклар

Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите

№8 Апрель, 2021 ел




***26 нчы апрель - татар дөньясы өчен истәлекле дата, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне. Ул татар шигъриятенең иң якты йолдызы, милләтебезнең йөзек кашы. Шагыйрь калдырган иҗат мирасы — безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Тукае булган халык бәхетле. Габдулла Тукай туган көн – Туган тел көне ул.***

***Балалар, тәрбиячеләр һәм ата-аналар, сезне чын йөрәктән Туган тел көне уңаеннан тәбрик итәбез.***

***Котлы булсын ил рухланып***
***Бәйрәмиткән Тукай көне.***
***Тукай көне, Тукай көне –***
***Туган телнең туган көне!***

***Татар теле тәрбиячесе Д.Р.Гыйниятуллина***

## Бүгенге санда

1. Г.Тукайга- 135 ел
2. “Миллимультfest»
3. «Нурчыклар» мультстудиясе
4. «Читек маҗарасы”
5. Тукай безнең күңелләрдә

# Читек маҗарасы

***Февраль аенда Буада «Милли мультfest» Республика балалар кинофестиваленең зона туры узды. Бәйгедә безнең “Нурчыклар” мультстудиясе тәкъдим иткән ”Читек маҗарасы” мультфильмы да катнашты. Бәйге нәтиҗәләре буенча безнең мультфильм зона этабын үтеп, республика этабында катнашу хокукына ия булды.***

***26 нчы апрельдә Казанда«Милли мультfest» кинофестиваленең финал этаплары уза.***

***Түземсезлек белән нәтиҗәләрне көтәбез. “Читек маҗарысы” мультфильмының барлыкка килүе турында 2 биттә укый аласыз.***

***QR код ярдәмендә әлеге мультфильмны карарга да мөмкин.***




# Нурчыклар мультстудиясе

## "Читек маҗарасы" мультфильмы

“Нурчыклар” мульстудиясе 2020 елда төзелде, аның исеме “Кояшкай” балалар бакчасына бәйле. Безнең балалар - кояш нурчыклары. Матур сөйләп, җырлап, биеп үсеп киләләр. Киләчәктә аларны күп эшләр, уңышлар көтә. Мультстудиягә төрле яшьтәге 15 бала йөри. Алар үз куллары белән мультфильм барлыкка китерәләр. Балалар төрле мультфильм ясау техникаларын өйрәнәләр.Үзебез ясаган “Читек маҗарасы” мультфильмы белән “Миллимультfest” бәйгесендә уңышлы чыгыш ясадык. Әлеге мультфильм ясауда мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче: Исхаков Раян, Газизуллина Әминә, Камалов Рамазан, Ахтямов Самат, зурлар төркемендә тәрбияләнүче - Ибрагимова Камилла катнашты.













Габдулла Тукай хәзерге Арча районының Кушлавыч авылында 1886 елның 26 апрелендә Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Малай туып биш ай үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Мәмдүдәне (Габдулланың әнисен) Сасна мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Шунда аның газаплы, авыр тормышы башлана. Бераз соңрак әнисе баланы үзе янына ала. Ләкин бәхетле чаклар озакка булмый: әнисе дә вафат була. Үги атасы Габдулланы, озак та тормастан, әнисе ягыннан бабасына - Өчиле авылына кайтарып җибәрә. Ә инде бу гаиләдә балалар болай да күп була, шуңа Апуш күп кыенлыклар кичерә. 1895 нче ел башыннан Тукай Уральск шәһәрендә яшәүче тугангары гаиләсендә тәрбияләнә. Биредә ул татар халык иҗатын һәм әдәбиятын җентекләп өйрәнә, гарәп, фарсы, төрек, рус һәм башка халыкларның әдәбиятлары белән таныша, рус теле аркылы Көнбатыш классик әдәбияты казанышларын үзләштерә. Үзе дә беренче шигырьләрен иҗат итә.

Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була. 1966 нчы елдан башлап, 26 нчы апрель - Г.Тукай туган көн - республикабызда шигырь бәйрәме буларак билгеләп үтелә. Еллар үткән саен аның бөеклеге арта гына бара.

## *Тукай безнең күңелләрдә...*















# Тукай мультфильмнары

**Мультфильмнарны QR код аша кереп карарга мөмкин**



















*Ялларыгыз күңелле үтсен...*

«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы: Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гиниятуллина Д.Р.
Шакирова Г.Р.

Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru